• ВАКЫЙГА •
ТАТАР ТЕЛЕ КУРСЛАРЫ УЗДЫРЫЛА
*2 бит*

• МИНБӘР •
ГАИЛӘ ТАРКАЛУНЫҢ БАЛАЛАРГА ЙОГЫНТЫСЫ
*4 бит*

• САБЫЙГА •
КОРЪӘНДӘ ИСКӘ АЛЫНГАН БАЛ КОРТЫ
*9 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •
ХАКЫЙКЫЙ МӨСЕЛМАННАР
*12 бит*

*№ 9 (302)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *сафәр 1442*

*Сентябрь, 2020*

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ




Гошер садакасы – Ислам баганаларының берсе булган зәкятнең бер төре. Аны бирү һәрбер мөселман кешесенең изге бурычы. Гошер садакасын биреп, мохтаҗ кешеләрне куандыру мөэмин кешене Аллаһыга якынайта, аңа исәпсез әҗерләр бирә…

***Дәвамы 3 нче биттә***

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Яңа Думада мәчет төзекләндерелде

## Аксубайның Яңа Дума авылында төзекләндерүдән соң мәчет ачылды



23 нче сентябрьдә, өйләдән соң Аксубай районы Яңа Дума авылында төзекләндерүдән соң тантаналы төстә мәчет ачылышы узды. Чарада Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Күпләгән кунаклар, рәсми җитәкчеләр, дин әһелләре, иганәчеләр, мәхәллә халкы әлеге күркәм вакыйганың шаһитләре булды.

Мәчет ачылышы Коръән аятьләре уку һәм әлеге мөбарәк тантанага килгән кунаклар белән таныштырудан башланып китте.

Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча киңәшчесе, казый, Аксубай районы имам-мөхтәсибе Равил хәзрәт Зөфәров Коръән укып дога кылды. Шуннан соң Аксубай районы башлыгы Камил Камал улы Гыйльмановка, ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Готыф улы Әхмәтовка, ТР Дәүләт Советы депутаты Рәис Әхтәм улы Сөләймановка, ТР Урман хуҗалыгы министры Равил Әфрәим улы Кузюровка сүз бирелде.

Аннары мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин әлеге җирлектә төзекләндерелеп, мәһабәт гыйбадәт йортының кабаттан үз ишекләрен ачу тантанасына җыелучыларны сәламләп, аның буш тормавын, һәрвакыт халык, балалар, яшьләр белән тулы булсын дип теләкләрен җиткерде. Ул гамәлләрнең фазыйләтләре хакында, мәчетләр, гыйбадәтләр, Аллаһы юлында кылган игелекләр хакында бәян итте, аннары Равил Кузюровка, Рәис Сөләймановка рәхмәт хаты һәм нәзарәтнең «Бердәмлек» медален тапшырды. Мөфти шулай ук Яңа Дума авылы мәчете имам-хатыйбы Фәнис хәзрәт Низамовка чапан, мәчеткә шәмаил бүләк итте. Чара барышында Равил Кузюров белән Рәис Сөләймановның әтиләренә Коръән мәгънәләренең татар теленә тәрҗемәсе – «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасын тапшырды.

Соңыннан тәкбирләр әйтелеп, тасмалар киселеп, мәчеткә кереп намазлар укылды, гыйбадәтләр кылынды.

Бүгенге көндә Аксубай мөхтәсибәтендә 28 мәчет эшли. Яңа Дума авылы мәчете 1991 елдан алып 1994 еллар аралыгында төзелә. Ә аңа кадәр намазларны өйдән өйгә укып йөргәннәр. Әлеге мәчет төзелешендә ике бригада: Гыйззәтов Шакир Нәмәтулла улы җитәкчелегендәге балта осталары һәм Хаматгатин Габделәхәт Хаматгата улы җитәкчелегендәге бина күтәрүчеләр катнаша. Шушы ике бригада эшләп, мәчетне дүрт ел эчендә күтәреп куялар. 1994 елның 10 июнендә мәчетнең ачылышы була. Анда Татарстанның баш казые Габделхак хәзрәт Саматов катнаша. Быел ТР Урман хуҗалыгы министры Кузюров Равил Әфрәим улы, ТР Дәүләт Советы депутаты, «Агро Инвест» компаниясенең генераль директоры Сөләйманов Рәис Әхтәм улы җитәкчелегендә мәчет яңартыла, капиталь ремонт ясала. Киләсе елга мәчеткә 30 ел тула.

# Татар теле курслары уздырыла

## Татарстанның 100 мәчетендә татар теле курсларына укучылар кабул ителә

1 нче октябрьдән Татарстан мәчетләрендә яңадан татар теле курслары башлана: яңа уку сезонында дәресләр 100 мәйданчыкта оештырылачак. Республикабызның барлык шәһәрләрен һәм күпчелек район үзәкләрен колачлаган татар телен өйрәнү буенча мәчет каршындагы курслар быел нәзарәт тарафыннан дүртенче тапкыр үткәрелә. Курслар ТАССР оешуның йөз еллыгы һәм нәзарәт тарафыннан игълан ителгән Туган тел елы кысаларында уздырыла.

2020-2021 уку елында татар телен башлангыч дәрәҗәдә өйрәнү буенча курслар Татарстанның 45 мөхтәсибәтен, шул исәптән Казанның 45 мәчетен колачлаячак. Тел өйрәнү дәресләре Рәсәй ислам институтында эшләнгән методика һәм дәреслекләр буенча үткәреләчәк. Хәзерге вакытта курслар узачак мәчетләрдә бүлмәләр барлык уку кирәк-яраклары, әсбаплар белән тәэмин ителде, техник чаралар белән җиһазландырылды, Татарстан мөхтәсибәтләре аша дәреслекләр таратылды. Моннан тыш, дәресләр үткәргәндә коронавирус инфекциясе таралуны булдырмый калу өчен барлык санитар-эпидемиологик таләп-ләр исәпкә алыначак: укучы-ларның медицина битлеклә-реннән килүләре һәм мәчеткә кергәндә антисептиклардан файдаланулары мәҗбүри булачак.

Мәчетләрдә татар теле дәресләре атнага ике тапкыр узачак. Укыту курсы 48 академик сәгатькә исәпләнгән, аның дәвамлылыгы 6 айны тәшкил итәчәк (2020 елның 1 октябреннән 2021 елның 30 апреленә кадәр). Дәресләрне үткәрү вакыты курсларга йөрүчеләрнең теләген исәпкә алып билгеләнәчәк. Тәҗрибә буенча, алар кичке сәгатьләргә туры килә. Интенсив курс программасы татар теленең сөйләм дәрәҗәсен өйрәнүгә, ситуатив лексик җыелмаларны үзләштерүгә һәм аралашу күнекмәләрен үстерүгә юнәлдерелгән. Моннан тыш, теләк буенча ислам дине мәдәнияте белән танышу, шулай ук тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнү өчен өстәмә мөмкинлек каралган.

Дәресләрне югары белемле филологлар, тәҗрибәле татар теле укытучылары алып барачак. Укыту процессында ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм «Хозур» нәшрияты тарафыннан Рәсәй ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы белгечләре белән берлектә әзерләнгән махсус дәреслегенең төзәтелгән һәм тулыландырылган басмасы файдаланылачак. Шушы көннәрдә әлеге уку әсбабы камилләштерелеп, Федераль белем бирү стандартларына туры китереп, кыска вакытлы курсларда белем алучылар өчен махсус төзелде һәм төсле иллюстрацияләр белән баетылып, 2500 данә тираж белән нәшер ителде. Дәреслекне тулыландыру буенча өстәмәләр кертелгәндә мөгаллимнәрнең теләк-тәкъдимнәре исәпкә алынды. Темалар, аларның бирелеше саклалса да, кайбер грамматик материал гадиләштерелде, өлешләргә бүленеп тәкъдим ителде. Лексик тема кысаларында зур булмаган яңа диалоглар, күнегүләр кертелде.

2019-2020 нче уку елында республикабыз мәчетләрендә узган татар теле курсларын 436 тыңлаучы уңышлы тәмамлады һәм телне башлангыч дәрәҗәдә үзләштерү хакында сертификатларга лаек булды. Гомумән, Татарстан мәчетләрендә татар теле курсларын оештыру тәҗрибәсе 2018 елдан бирле тормышка ашырыла. Барлыгы әлеге курсларны 1327 кеше тәмамлады.

Мәчет каршындагы татар теле курсларына башлангыч сөйләм дәрәҗәсендә белем алырга ниятләгән барлык теләге булучылар чакырыла. Укыту бушлай. Курсларда белем алу өчен 1 октябрьгә кадәр мәчетләргә мөрәҗәгать итеп язылырга кирәк.

■ dumrt.ru сайтыннан

# 10 тонна гошер таратылды

## «Зәкят» фонды бер сәгать эчендә мохтаҗларга 10 тонна гошер таратты. Акция дәвам итә



Гошер садакасын җыеп тарату буенча кампаниянe ТР мөселманнарының Диния нәзарәте 15 сентябрьдә игълан иткән иде. Бу уңайдан җыеп алынган уңышның уннан берен мохтаҗларга өләшү буенча хәйрия акциясе кысаларында бүген Питрәч мөхтәсибәте "Зәкят" фондына 10 тонна гошер садакасы җибәрде. Моңарчы Казанның мохтаҗ гаиләләренә 1,5 тонна яшелчәне Алексеевск, Әтнә, Балык Бистәсе, Питрәч мөхтәсибәте алып килгән иде. Гошер итеп мохтаҗлар карамагына тапшырылган яшелчәләрдән иң зур күпчелекне бәрәңге, аннары чөгендер, кишер, кабак һ.б. тәшкил итә.

Питрәч районында гошер садакасын җыю айлыгы 10 сентябрьдән 10 октябрь аралыгына билгеләнгән. Моңа кадәр җыелган 5 тонна гошер садакасы Питрәчнең үзендә яшәгән мохтаҗларга таратылган. Ә бүгенге 10 тонна гошер уңышын мөхтәсибәт вәкилләре "Зәкят" хәйрия фонды карамагында тәрбияләнүчеләр өчен тапшырырга карар кылалар. Гошер җыю эшендә Питрәч, Ленино-Кокушкино, Татар Тау иле, Шәле, Пимәр, Карповка, Чыты авыл җирлекләрендә яшәүче мөселманнар актив катнаша.

Гошер садакасын мохтаҗлар арасында бүлү һәм тарату тәртипләре, пандемия шартларында азык-төлекне өйгә китереп бирү тәҗрибәсе хакында "Зәкят" фондының генераль директоры Булат Мәрданов таныштырды: "Бүгенге 10 тонна гошер садакасы өч йөзгә якын гаиләгә таратылды. "Зәкят" фонды быел шул рәвешчә дүртенче машина гошерне казанлыларга өләште. Бүгенге көнгә 16,5 тонна яшелчә мохтаҗларга китте. Бер гаиләгә уртача 30-35 килограмм яшелчә туры килә. Фонд хезмәткәрләре исемлек төзиләр һәм аларны билгеләнгән вакытка чакыралар. Исемлеккә керү өчен "Зәкят" фондына килеп яисә әлеге номерга шалтыратып язылырга мөмкин: 225-33-22. Өеннән чыга алмаган авырулар өчен автоволонтерлар ярдәм күрсәтә, шулай ук машиналы кешеләр дә бер-берсенекен алып китәргә булышалар. Пандемия башланганнан бирле "Зәкят" фонды өйгә китереп бирү буенча тәҗрибә тупларга өлгерде. Корбан гаете көннәрендә ит, көз көне гошер садакалары йөри алмаучы инвалидларның өйләренә китереп бирә". Шунысы игътибарга лаек: «Зәкят» фонды аша 2018 елда 500, 2019 елда 1500, 2020 елда әлегә якынча 500 гаилә гошер белән тәэмин ителде.

– Шушы пандемия шартларында авыр хәлдә калганнарга Аллаһы Тәгалә Үзенең ярдәмен дә бирә. «Зәкят» фонды бик ярдәм итә. Аларга Аллаһы Раббыбыз эшләрендә ярдәмнәрен бирсен, сәламәтлектән аермасын. «Зәкят» фондына гошер бирүчеләрнең садакаларын Аллаһы кабул итсен, иманнарын кабул әйләсен, пенсионерларны, мохтаҗ кешеләрне сөендерергә насыйп әйләсен. Безне кочак җәеп каршы алалар, бәрәңге, кишер, суган, чөгендер бирәләр. Моңа кадәр корбан итләре, киемнәр бирделәр, – дип рәхмәтләрен җиткерде Казаннан Рушания ханым.

Гошер – ул садаканың махсус төре, ул мөселман кешесенең үстергән уңышын җыеп алганнан соң, аның уннан берен мохтаҗларга бирүдән гыйбарәт. Гошер садакасының мәҗбүри булуы хакында «Әл-Бәкара / Сыер» сүрәсенең 267 нче аятендә болай дип әйтелә: **«Ий иман китерүчеләр! [Кәсеп итеп] Тапканнарыгызның иң яхшыларын [хәләлләрен] һәм Безнең сезнең өчен җирдән чыгарган нәрсәләребездән [садака итеп] сарыф итегез...»** Гошер садакасының мәҗбүри булуының асыл мәгънәсе – теләсә кайсы уңыш нигезендә Аллаһының рәхмәте ятуда, чөнки әлеге нигъмәтләр табигать шартларының уңай килүе нәтиҗәсендә өлгерә. Аллаһының рәхмәтенә ирешү һәм киләсе уңышка нигез салу өчен, Раббыбызның әмеренә буйсынып, Кәлам Шәрифтә әйтелгәнчә, уңышның гошерен (уннан берен) бирергә кирәк. Гошер зәкятнең бер өлеше булып тора.

Татарстан Диния нәзарәте әлеге юнәлешкә бик зур дикъкать белән карый. Республиканың барлык мәчетләре, мәдрәсәләр гошерне кабул итеп алырга һәм таратырга әзер. Һәр елдагыча гошер сыйфатында җиләк-җимеш һәм яшелчәләр: бәрәңге, кәбестә, чөгендер, кишер, кабак, суган, алма, слива, шулай ук кыш өчен кайнаткан һәм тозлаган әйберләр кабул ителә. Аннан соң азык-төлек җыелмаларын аз керемле, мохтаҗ кешеләргә тапшыру оештырылачак.

Казанда гошерне Нәзарәт карамагындагы «Зәкят» хәйрия фонды кабул итә һәм тарата. Фондта меңнән артык мохтаҗ гаилә исәптә тора. Аларның барысына да – күпбалалы, тулы булмаган, азкеремле, авыру балалар тәрбияләүче гаиләләргә гошер тапшырылачак. Әлеге исемлектә булмаган, әмма гошер рәвешендәге азык-төлекләтә ярдәмне алырга теләүчеләр Пенсия фондыннан керемнәр турындагы белешмә алып, +7 (843) 225-33-22 телефоны буенча шалтыратып фондка мөрәҗәгать итә ала. Гошер алып килергә теләүчеләр дә шушы ук телефонга шалтыратып мөрәҗәгать итә ала. Гомумән, гошер мохтаҗларның милләтенә һәм диненә карамыйча, аларның үзләренә, шулай ук хәйрия оешмаларына, социаль учреждениеләргә (район картлар йортлары, балалар йортлары, балалар хосписы), мөселман уку йортларына (мәдрәсәләргә, мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына, Коръәнхафизлар әзерләү үзәгенә һ.б.) тапшырылачак.

Татарстанда традицион рәвештә гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясендә катнашучылар саны елдан-ел арта бара: 2017 елда – 160 тонна, 2018 елда – 600 тонна, 2019 елда – 1109,5 тонна гошер садакалары җыеп таратылды.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Гаилә таркалуның балаларга йогынтысы



Ислам динендә гаилә коруга, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләргә зур игътибар бирелә. Аллаһы Тәгалә, гаилә әһелләре арасындагы хокукларның гадел рәвештә үтәлүен таләп итеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә шәргый кануннарын иңдергән. Әгәр кеше Аллаһы Тәгалә тыйган әйберләрдән ерак торса, рөхсәт иткән нәрсәләрне үтәсә, ике дөньяда да бәхетле була ала. Бары Галәмнәрнең Раббысы гына адәм баласына нәрсә бәхет китерәчәген белә.

Кызганычка, гаилә кору сараена бәхетле кавышу мизгелләрен теркәү өчен генә түгел, ә аерылышу турында белешмә алу өчен дә еш мөрәҗәгать итәләр. Әлбәттә, гаилә таркалуга барып җитүнең төрледән-төрле сәбәпләре бар: аралар суыну, хыянәт, ике яр арасына өченче затларның кысылуы, акча мәсьәләсе... Бу исемлекне һәрбер аерылышкан пар үз сәбәбе белән тулыландыра аладыр, мөгаен. Әмма бүгенге вәгазь талак, аның төрләре, сәбәпләре хакында түгел. Сүзебез гаилә корабы комга терәлгәннән соң, тормыш ярында башларын аска иеп утырып калган ятим балалар хакында.

Хәзерге вәзгыятьтә мөселманнар арасында талак әйтү гадәти күренешкә әверелеп бара. Әле бер яктан, әле икенче яктан: «Тегеләр гаилә таркалган икән, тегеләр бергә яшәмиләр, бу хатыннан башкага чыгып киткән, теге, ирен калдырып, әти-әнисе йортына кайткан икән», – дигән хәбәрләр ишетелеп тора. Кайберсенә ихластан шаккатасың, икенчеләре табигый хәл булып кабул ителә.

### Бала – гөнаһсыз сабый

Гаилә таркалуда гаебе булмаган бер генә тараф бар, ул – бала. Талакның иң көчле җимергеч дулкыны балалар өстенә төшә. «Ул әле кечкенә, аңламаячак, үскәч онытачак», – дип фикер йөртә өлкәннәр. Әмма бала – тере җан, ул сизә, тоя, ул ярата, ул тулы гаиләгә мохтаҗ, ул – ике яклы яратуга, назга сусаган бер чәчәк. Статистик мәгълүматларга карасак, һәрбер җиденче бала тулы булмаган гаиләдә тәрбияләнә.

Талак процессында ир белән хатын арасында төрле негатив вакыйгалар килеп чыга, һәм менә шул вакытта өченче зат – бала хакында онытырга кирәк түгел. Бала ничә яшьтә генә булмасын, ата белән ананың аерылышуы – аның өчен зур кайгы-хәсрәт.

Әйе, гаиләләр төрле була: кемдер бәхетле, ә кемдер бәхетсез. Бала өчен гаилә – ул зур бер әкияти сарай: әтисе – анда падишаһ, ә әнисе – патшабикә. Әмма бу фани дөнья камил түгел, һәм сарайлар да җимерелә, әкиятләр эреп юкка чыга.

Бик еш ата белән ана, үзләре дә сизмәстән, баланы бер-берсенә каршы салкын сугышта корал итеп кулланалар. Һәртөрле манипуляцияләр, баланы бер-берсеннән тартып алу өчен, янаулар, судлашулар – шушы исемлектән.

Бала күңелендә һәрвакыт әти белән әни яңадан кавышыр, бар да элеккегечә булыр дигән өмет яши. Икенче төрле вариантта – тулы өметсезлек: әти белән әни беркайчан да бер-берсен яратмаганнар, минем өчен генә кавышканнар, бөтен бәхетсезлекнең сәбәбе – мин. Бу ике сценарий да балада күпләгән психологик проблемалар – невротизм китереп чыгара. Балачакта алган психик яралар кешене гомер буе җибәрми, инде үз гаиләсен төзегән очракта да, балачак «яралары» әледән әле калкып, иректән бәхетле тормыш корырга ирек бирми.

### Балалар – ул әманәт

Балалар – ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә бирелгән әманәт. Күп кенә ир-атлар, аерылганнан соң, балаларын тәрбия һәм матди яктан кайгырту мәсьәләләрен хатыннары җилкә-сенә аудара, алимент түләүдән качып, рәсми рәвештә эшкә урнашмыйча йөри, йортсыз-җирсез калдыра. Барыбызга да үрнәк булган Расүлебезгә карагыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең балаларга карата мәхәббәте үз балалары белән генә чикләнмәгән. Үсәмә бине Зәйдтән риваять ителгән хәдистә әйтелгән: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм мине һәм Хәсәнне (оныгын) алдына утыртып, каты итеп кочаклап, Аллаһы Тәгаләгә дога кыла иде: Йә Раббым, Үзеңнең рәхмәтеңне шушы балаларга насыйп ит, чөнки мин аларны шулкадәр нык яратам» (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан). Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе сөйли: Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Хәсән бине Галине үбеп алган вакытта, янында Әл-Әкра бине Хәбис Әт-Тәмими утыра иде. Әл-Әкра сүз алып, болай дип әйтте: «Минем ун балам бар һәм мин аларны бер дә иркәләп үпкәнем булмады». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа күз карашын ташлап: «Кем дә кем башкаларга рәхмәтсез булса, үзенә карата да рәхмәт өмет итмәсен», – дип әйтте (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан). Икенче бер хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Аллаһыдан куркыгыз һәм үз балаларыгызга гадел мөнәсәбәт кылыгыз» (Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Әгәр дә без Мөхәммәд өммәтеннән икән, нигә талак әйткән вакытта, балаларыбызның киләчәк язмышы, сынган күңеле, түгеләчәк күз яшьләре турында уйлап та карамыйбыз? Бик еш хатынга карата ачуыбыз һәм күрә алмавыбыз балаларга да күчә. Сез аларны дөньяга кунак итеп чакыргансыз, Аллаһы Тәгалә сезгә аларны кадерле кунак итеп җибәргән, ни өчен сез аларны кадерсез, сөйкемсез, инде кирәкмәс бер зат итеп, тормышның «урамы читенә» атып калдырасыз?

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Чынлыкта, Кыямәт көненнән соң кеше лаек булмаган югары дәрәҗәдәге җәннәт бакчасына күтәрелер. Ул аптырап болай дип сорар: «Бу миңа нәрсә өчен?» Аңа: «Синең гөнаһларыңны гафу итүен ялварып сораган балаңның догалары өчен», – дип әйтелер (Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан). Әгәр син балаларыңны, әманәтеңне ташлап аерылып чыгып киткәнсең икән, ничек итеп син аларны иман нурында тәрбия кыла алачаксың? Догачың кем булыр, кардәшем?

Габдулла бине Гамер радыяллаһу ганһүмәдән риваять ителә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үзендә шушы дүрт сыйфатны тапкан кеше чын монафикъ булыр, ә кем үзендә шул дүрт сыйфатның берсен тапса, аннан котылганчы монафикъ галәмәтендә булыр. Әлеге сыйфатлар белән аерыла торган кеше шундый: әманәтенә хыянәт итә, ялган сөйли, сүзендә тормый, кем беләндер дошманлык кылганда, гамәлләрендә чигеннән чыга» (Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

### Кайсын теләр идегез?

Үзегезнең балачакка әйләнеп кайтыгыз. Күз алдыгызга китерегез: иртәнге кояш нуры сезне уята, сезгә 4-5 яшьләр тирәсе. Өегездә җылы, рәхәт. Юрганны алып атып, аш бүлмәсенә йөгерәсез. Әниегез тәмле коймаклар пешерә, әтиегез кайнар чәй белән коймак ашый. Сезне күргәч, әтиегез кочаклап, алдына утырта. Әниегез, хәерле иртә теләп, башыгыздан сыйпый.

Икенче күзаллау да бар. Уянасыз. Өйдә тын. Якшәмбе. Димәк, әни эштә түгел, өйдә. Торып, аш бүлмәсенә чыгасыз. Әниегез чәй эчеп утыра. Сезгә тонык кына караш ташлый да: «Әйдә, юын да чәй эч. Хәзер әтиең килеп алыр. Үзең киенеп аска төшәрсең», – ди. Атна-ун көнгә бер тапкыр сезнең әтиле көнегез дә бар, әмма эти һәм әниле түгел.

Кайсы күңелгә җылы һәм рәхәт? Ә кайсысы күңелне өшетә, җанны биздерә?

Үз балагызга сез кайсысын теләр идегез?..

■ **Ирек хәзрәт Нуриев, Менделеев районы мөхтәсибе**

# Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасы

***Дәвамы. Башы алдагы санда***

## Исмәгыйль галәйһиссәлам корбан ителергә тиеш

Ел саен Ибраһим галәйһиссәлам Мәккәгә үз гаиләсе янына килә торган була. Еллар үтә, Исмәгыйль галәйһиссәлам үсеп буйга җитә, Ибраһим исә әйткән нәзере турында оныта... Ләкин көннәрдән бер көнне эти кешегә әйткән вәгъдәсен исенә төшерәләр – ул төш күрә. Аңа:

– Ий Ибраһим! Аллаһы әмере белән улыңны корбан ит, – дип әйтелә.

Йокысыннан уянгач, Ибраһим галәйһиссәлам бу төшнең шәйтаннанмы яки Рәхманнанмы икәнлегенә шикләнә башлый. Фәхретдин Әр-Разый, Хазин һәм казый Бәйдави моны болай дип аңлаткан. Ибраһим галәйһиссәлам төшне Гарәфә көне алдыннан күрә. Күңеленә шөбһә төшергәнгә күрә, зөлхиҗҗә аеның 8нче көне Тәрвия көне дип атала башлый. «Тәрвия» – шикләнү дигән сүз.

Гарәфә көнендә дә шул ук төшне күргәч, Ибраһим галәйһиссәлам аның Аллаһыдан булуын аңлый, бөтен шик-шөбһәләр юкка чыга. Әмма Раббысының бу әмерен кайчан үтисе?

Өченче тапкыр да әлеге төшне күргәч, ата үз баласын шушы көндә үк корбан итәргә тиешлеге ачыклана. Ибраһим галәйһиссәлам Исмәгыйль галәйһиссәламне корбан итү урынына алып китә. Соңыннан бу көн «Яумун-Нәхр / Корбан бәйрәме» дип атала башлаячак.

Юлда Ибраһим галәйһиссәлам янына карт кыяфәтенә кереп шәйтан килә:

– Ашыкма, бәлки, Аллаһы Тәгалә бу җаваплылыктан сине арындырыр. Улыңа кара: нинди чибәр, сәламәт, төз гәүдәле егет! Үз балаңа пычак кадарга әзер булгач, нинди ата син?!

Шәйтанның бу сүзләрен ишеткәч, Ибраһим галәйһиссәлам:

– Әй каһәр суккан шәйтан! Күземнән югал. Бу – Раббым әмере. Мең улым булса, Аллаһы ризалыгы өчен аларны да корбан итәргә әзер булыр идем, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәламне юлдан яздырудан өмет өзеп, шәйтан Исмәгыйль галәйһиссәлам янына да барып карый:

– Атаң сине кадап үтерергә алып бара. Пычагын күрдеңме?

Исмәгыйль галәйһиссәлам:

– Ата кеше үз баласын үтерә аламыни?! Ни сөйлисең син? – дип әйтә.

– Аңа Аллаһыдан шундый әмер килә.

– Раббымның теләге шундый булгач, синең ни эшең бар, мәлгунь?! – дип, Исмәгыйль галәйһиссәлам шәйтанга таш атып куып җибәрә.

Кырын эшен болай да майтара алмагач, шәйтан хәзрәти Һаҗәр янына юнәлә, әмма аны куркыту да көченнән килми – Ибраһим галәйһиссәлам гаиләсе аңа каршы нык тора.

Бераздан соң Җир күз күрмәгән, колак ишетмәгән бер могҗизалы вакыйгага шаһит була. Коръәндә болай дип әйтелә:

**«Ул аның белән бергә [эшләрендә] тырышлык куюга [мөмкинлек биргән унөч яшьләргә] җиткәч [атасы аңа]: «Ий улым! Һичшиксез, мин [берничә төн рәттән] төшемдә сине чалганымны күрдем. Син ни уйлаганыңны кара», – диде. Ул: «Ий әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне [һич уйлап тормыйча] үтә. Иншә Аллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың», – диде».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:102

Күргәнегезчә, сынауның авырлыгына карамастан, Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең әмеренә бер дә каршы килми, аңа берсүзсез күнә. Йөрәгендә һичнинди кайгыру һәм борчылуга да урын калдырмаган итагать күрсәтә. Ә Исмәгыйль галәйһиссәлам атасыннан Яратучының шушы теләгән ишеткәч, үзенең көчле иманы һәм күңеле белән Ибраһим галәйһиссәламнең итагатьлек дәрәҗәсенә ирешә:

**«Ул: «Ий әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне [һич уйлап тормыйча] үтә. Иншә Аллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың», – диде».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:102

Бу бик мөһим сүзләр. Исмәгыйль галәйһиссәлам корбан китерергә кирәклеге турында ишеткәч тә, атасына карата мәхәббәтен җуймый, шушы авыр мизгелдә аның хәленә керә, теләгенә күнә. Ничек кенә кыен булса да, барыбер яратып «Атам минем» дип эндәшә һәм әдәбен дә саклый. Хәтта Аллаһыны да элек олылаган кебек олылый. «Иншә Аллаһ!» ди. Үзен батыр итеп күрсәтеп, мактау сүзләрен ишетү өчен түгел, ә сабыр һәм тәкъвалы булып каласы килә аның. Шуннан да югарырак фида кылу мөмкинме?

## Бөек сынау күренеше

Ачыктан-ачык сөйләшүдән соң Ибраһим галәйһиссәлам һәм Исмәгыйль галәйһиссәлам әмерне үтәүгә әзерләнә башлыйлар. Аларның икесе дә берничә мизгелдән дөньяда булмаган, кеше аңы сыйдыра алмаган, Изге Коръән китабында мәңгелеккә сакланып калынган һәм буыннан-буынга сөйләнә торган олы вакыйганың шаһитлары булачагы турында әле белми. Раббыбыз болай дип әйтә:

**«Ул икәү [Аллаһы Тәгаләнең хөкеменә тулысынча] буйсынгач, ул аны яны белән [җиргә] яткырды».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:103

Мондый сынауны кешелекнең бүтән күргәне булмады. Хәтта фәрештәләр дә Ибраһим галәйһиссәлам һәм Исмәгыйль галәйһиссәламнең ихлас гамәлен тын да алмыйча күзәтеп тора. Ниһаять, ата үз улының муенына пычак тидерә. Ләкин пычак кисми, Исмәгыйль галәйһиссәламнең бер тамчы каны да чыкмый. Ибраһим галәйһиссәлам пычакның үткенлеген тикшерә – пычак ташны яра, әмма Аллаһының бөек хикмәте белән кеше муенын кисми.


Шулчак Ибраһим галәйһиссәлам ачу белән әйтә:

– Әй пычак! Син минем Раббыма итагатьсезлек күрсәтүемне телисеңме?

Пычак болай дип җавап бирә:

– Хәлил кисәргә куша, Җәлил кисмәскә куша. Миңа нишләргә? Әлбәттә, мин Аллаһы Тәгалә сүзен генә тыңлыйм.

Әнә шулай итеп, ике бөек тәкъвалы кеше Раббыбызга үзләренең тугрылыкларын дәлилли. Атага һәм аның газиз улына Аллаһы ризалыгы өчен корбан итәргә сарык җибәрелә.



**«Һичшиксез, бу – ап-ачык бер сынау. Без аңа фидия итеп зур [кыйммәткә һәм гәүдәгә ия булган] бер корбанлык [сарык тәкәсе] бирдек».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:106-107

Шулвакыт күктән тәкбир әйтеп, Җәбраил галәйһиссәлам төште. Аның кулында корбанга китерелергә тиешле сарык иде. Җәбраил галәйһиссәлам:

– Аллаһү әкбәр! Аллаһү әкбәр! – дип тәкбир әйтте.

Ибраһим галәйһиссәлам башын өскә күтәреп: «Ләә иләәһә илләллаһу вәллаһү әкбәр», – диде.

Исмәгыйль галәйһиссәлам бу сүзләрне ишетеп: «Аллаһү әкбәр вә лилләһил хәмде», – дип әйтә.

Менә шушы вакыйгадан соң Корбан гаете көннәрендә мөэмин-мөселманнар һәр фарыз намазыннан соң бердәмләшеп тәкбир-тәшрикъләрне кабатлый башлый. Тәкбирләрне әйтү Гарәфә көненең иртәнге намазыннан башлап, бәйрәмнең дүртенче көнендәге ястү намазына кадәр башкарыла.

Шулай итеп, Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең сынавын үтәп, Аңа үзенең тәкъвалыгын һәм тугрылыгын исбатлый. Раббыбызга үзенең чиксез иманын күрсәтеп, ул Хәлилуллаһ, ягъни Аллаһының дусты дигән олы исемгә лаек була. Без исә шуны аңладык: сөекле Яратучыбыз Үзенең колларыннан сабырлык, диндарлык һәм ихлас иманнан башка берни таләп итми. Ул бушка китерелгән корбаннардан да риза булмый. Әмма ихластан Аның ризалыгы өчен шәхси милек һәм гомерне корбан итәргә әзер булуыбыз, Аллаһы Тәгалә әмеренә буйсынуыбыз Аңа ихластан гыйбадәт кылуыбызны дәлилли. Хәлилуллаһ шундый булган!

Шушы гыйбрәтле кыйссадан аңлашыла ки, Ибраһим галәйһиссәламнең башына төшкән барлык сынауларның максаты газиз баласының гомерен өзү түгел, ә йөрәгеннән Аллаһы Тагәләдән кала башка мәхәббәтләрне сөртеп ташлау була. Кулына пычак алып, Ибраһим галәйһиссәлам Исмәгыйльне түгел, ә аңа карата сөюен кисеп, күңелендә бердәнбер бөек илаһи яратуны гына калдыра.

Аллаһы теләмәсә, бернинди үткен пычак кисә, бернинди ут яндыра, бернинди диңгез суга батыра алмаячак. Ибраһим галәйһиссәлам һәм Муса галәйһиссәламнең гыйбрәтле мисаллары – безгә үрнәк булыр.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие**

# Зыян китермә, сиңа да зыян булмас

Барчаларыбызны да юктан бар кылып, безне билгеле бер вакытка кадәр шушы сынау дөньясына урнаштырган; тирә-ягыбызда булган һәрнәрсәне безгә хезмәткә тапшырган; безгә күрү өчен – күз, ишетү өчен – колак, уйлау, фикерләү өчен аң-белем биргән; безгә нигъмәтләрнең иң югарыларын – иман, ислам, Коръән, намаз, гыйбадәт нигъмәтләре насыйп иткән; барча мәхлүкъларын Кыямәт көнендә Үз каршына китереп бастыручы; һәркайсына хисап кылып, гадел хөкем итүче; кемнедер җәннәтле, ә кемнедер җәһәннәмле итүче, гыйбадәткә лаек булган бердәнбер Зат Аллаһыга мең-мең шөкерләребез, мактау-олуглауларыбыз булсын.

Безгә шушы хак динебезне өйрәткән, җәннәт юлы белән сөендергән, җәһәннәм юлы белән кисәткән, үзенең кылган һәрбер эше белән, үзенең әдәбе-әхлагы белән, үзенең тормыш рәвеше белән һәркемгә үрнәк булган, безнең өчен газиз әткәй-әнкәйләребездән, бабай-әбиләребездән, кадерле бала-оныкларыбыздан һәм үз-үзебездән дә якын булган сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, Кыямәт көнендә, иншәАллаһ, шәфәгатьчебезгә күңел түрләребездән чыккан хәер догаларыбыз, Аллаһының сәламе һәм салаваты булсын!

Газиз кардәшләрем! Иң беренче чиратта, үземне, аннан соң сезне тәкъвалыкка чакырам. Аллаһының әмерләрен үтәгез, тыйганнарыннан ерак торыгыз! Һәм белегез: Адәм баласының бу дөньядагы бәхете дә һәм Кыяматтә Аллаһының рәхмәте белән җәннәткә керүе дә кешенең бу дөньяда булганда тәкъвалыгына кайтып кала. Аллаһының әмерләрен ничек үтәде?! Аллаһының харамнарыннан ничек тыелды?! Аның дөньядагы һәм Ахирәттәге иминлеге шуның белән бәйле. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

**«Ий иман китерүчеләр! [Әмерләрен тотып, тыйганнарыннан тыелып] Аллаһыдан тиешенчә куркыгыз һәм мөселманнар булып кына үлегез!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кыска җөмләләр белән киң мәгънәгә ия булган хәдисләр сөйләгән. Менә шундый хәдисләрнең берсе: Әбү Сәгыйд Сәгъд бине Синән Ходри радыяллаһу ганһе әйтүенчә, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Исламда зарар кылу һәм (җавап итеп) зарарлык китерү юк», – дип әйткән (Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан). Игътибар итегез, нибары биш кенә сүз, ләкин нинди тирән мәгънәләре бар:

1. «Сәбәпсез (беренче башлап) зарар китерү дә, җавап итеп (сиңа зарар эшләүчегә үч итеп) зарар китерү дә тыела».

2. Зарар ителәчәк икәне алдан билгеле булса, туктату чарасын күрү; зарар инде эшләнгән булса, аның өчен җавап бирү (бәхилләп булса бәхилләү, штраф түләп булса – штрафын түләү, гафу сорау һ.б.)».

3. «Үзеңә һәм башкаларга зарар итмәү».

Бу хәдис үзе бик кыска гына булса да, үз эченә динебезнең төп кагыйдәләрен сыйдырган. Зарар кылу – хакны кысу, зыян китерү, үзеңнең яки башкаларның хакына кимчелек ясау. Болар барысы да тыелган нәрсәләр. Ислам дине – билгеле булганча, кешенең динен, сәламәтлеген, гомерен, акылын һәм намусын саклый торган дин. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтүенчә: «(Чын) мөселман – кулыннан һәм теленнән башкалар иминлектә булган кеше» (Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан). Һәм икенче бер хәдистә: «Үзегезгә теләгәнне кардәшләрегезгә теләмичә торып, берегез дә (камил) иманлы булмас», – дип әйтелә (Имам Бохари һәм Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан). Димәк, чын мөселман һәм камил мөэмин дәрәҗәсенә ирешер өчен, кешеләргә зыян-зарар китерүдән сак булырга, үзебезгә теләмәгән нәрсәләрне бүтәннәргә дә теләмәскә кирәк. Нинди генә эш эшләсәң дә, ул эшеңне җиренә җиткереп, югары сыйфатта башкарырга тырыш. «Минем эшләгән эшемнән башкаларга зыян килмәсен иде», – дип эшлә.

## Үзеңә дә зарар китермәскә тиеш!

Кеше үзенә ничек зарар китерә ала? Бу ничектер сәеррәк яңгырый бит. Мәсәлән, хәзерге заманда үз-үзенә кул салучы кешеләр турында ишетергә туры килә. Аларның кайберләре бауга менә, кайберләре агу эчә, кайберләре үз-үзенә пычак кадый, ә кайберләре биеклектән сикереп, үз-үзләренә кул салалар. Бу күренеш олылар арасында гына түгел, ә хәтта мәктәптә укучы балалар арасында да, яшь кызлар һәм егетләр арасында да күзәтелә. Кешенең үз-үзенә кул салуының сәбәпләре төрле. Хәзерге вакытта шуларның иң киң таралганнары түбәндәгеләр: яраткан кеше белән аерылышу, гаиләдә ир белән хатын арасында даими ызгыш-талаш, эшсез калу, бурычка бату, эчкечелек һәм наркомания.

Үз-үзеңә кул салу – бик зур гөнаһ! Аллаһы Тәгалә бу гамәлне харам кылды. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

**«Үз-үзегезгә кул салып яки җаныгызны куркыныч астына куеп] Үзегезне үзегез үтермәгез. [Ий Мөхәммәд өммәте!] Аллаһы сезгә карата Рәхимле…»**

«Ниса / Хатыннар», 4:29

Ни өчен кеше үзен үтерергә дип карар кыла? Моңа аны нәрсә этәрә? Кешене үз-үзенә кул салуга, иң беренче чиратта, төшенкелеккә бирелү хисе ягъни Аллаһының рәхмәтеннән өметне өзү этәрә. Кеше төшенкелеккә бирелсә, аның бу дөньяда яшисе килми башлый. Ул бу дөньядагы проблемалардан үз-үзеңә кул салу юлы белән «җиңел генә» котылмакчы була. Үзе һәлак була, ә туганнарына, балаларына, әти-әниләренә күпме кайгы хәсрәт китерә…

Ә кайвакытта кешеләр үзләрен махсус булмаган рәвештә, ялгыш һәлакәткә дучар итәләр. Моның мисаллары күп төрле, мәсәлән: көн саен юл һәлакәтләре турында хәбәрләр килеп тора. Машинада йөргәндә, тизлекне арттырып, юл кагыйдәләрен бозып, күпме кешеләр һәлакәткә очрый, еш очракта анда үзе генә имгәнми, үзе генә үлми, үзе белән күпме кешене имгәтә, һәлак итә. Күпме зарар китерә.

Тагын да куркынычы Ахирәттә җәһәннәм газабына дучар була. Аллаһы Тәгалә һәр кешегә дә җанны әманәт итеп бирде. Әманәт – ул сакларга бирелгән әйбер. Җан – ул бик кадерле нәрсә. Кеше Аллаһы биргән җанны гомере буе сакларга тиеш. Җанны саклау ул үз-үзеңә зыян китерә һәм һәлакәткә алып бара торган бөтен нәрсәдән саклануны аңлата.



Җөндүб радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән хәбәр итә: «Бер кеше җәрәхәт аркасында үз-үзен үтерде. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: Колым үз-үзен үтереп Мине узды. Шуңа күрә Мин аңа җәннәтне харам кылдым» (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук: «Кем дә кем таудан сикереп үз-үзен үтерсә, җәһәннәмдә мәңге калган хәлдә (таудан) сикерәчәк. Кем дә кем агу эчеп үз-үзен үтерсә, кулында агуын тотып, җәһәннәмдә мәңге калган хәлдә, агу эчәчәк. Кем дә кем тимер белән үз-үзен үтерсә, җәһәннәмдә мәңге калган хәлдә, кулындагы шул тимерен корсагына кертәчәк» (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

Бу хәдистән аңлашылганча, кеше үз-үзенә берәр нәрсә белән кул салса, җәһәннәмдә дә шуның белән яки мәңге яки бик озак вакыт дәвамында газап күрәчәк.

Галимнәр әйтүенчә, үз-үзен үтергән мөселман кеше юыла, кәфенләнә. Аңа хәнифә һәм шәфигый мәзһәбләрендә җеназа намазын укыйлар. Башка кешеләргә сабак булсын өчен, сөннәт буенча аңа җеназа намазын имам яки галим кеше укымый. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә андый кешеләргә намаз укымый торган булган. Җабир бине Сәмура хәбәр итә: «Бер вакытны Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына үз-үзен үткен нәрсә белән үтергән кешене алып килделәр, һәм ул аңа җеназа намазы укымады». Бу хәдисне галимнәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз-үзен үтергән кешегә җеназа намазын, башкаларга дәрес, гыйбрәт булсын һәм башкалар бу гөнаһтан саклансыннар өчен, укымады, дип аңлаталар.

Үз-үзен үтергән кеше өчен Аллаһы Тәгаләдән җәһәннәм газабыннан коткаруны һәм җәннәткә кертүне сорап, дога кылырга ярый. Кыямәт көнендә бу кешенең хөкеме Аллаһының теләгенә бәйле. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә теләсә, аны гафу итә, әгәр дә теләсә, аны газаплый.

Йә Раббым, һәммәбезне дә үз-үзебезгә карата һәм башкаларга да зарар китерүдән сакласаң иде!

■ **Гәбделкәрим хәзрәт Гыйззәтуллин**
**Әгерҗе районы мөхтәсибе**



## Төшенкелеккә бирелүдән дога

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Сөннәттә төшенкелеккә бирелүдән дога бармы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Әйе, Коръәндә дә, Сөннәттә дә борчылудан, сагыштан, күңелсезлектән, төшенкелеккә бирелүдән дога бар.

1.

اللّٰهُمَّ إِنّي أَعْوذُ بِكَ مِنَ الهَمِّ والْحُزْنِ، والعَجْزِ والكَسَلِ والبُخْلِ والجُبْنِ، وضَلْعِ الدَّيْنِ وغَلَبَةِ الرِّجال (صحيح البخاري ٢٨٩٣)

Аллаһуммә инни әгүҙү бикә минәл-һәмми вәл-хузни, вәл-гаҗзи вәл-кәсәли вәл-бухли вәл-җүбни, вә-далги-д-дәйни вә-галәбәтир-риҗәәл.

Мәгънәсе: «Йә Раббым, Синнән тынычсызлыктан, сагыштан, көчсезлектән, ялкаулыктан, саранлыктан, куркаклыктан, әҗәт колы булудан һәм кешеләрнең кимсетүеннән саклавыңны сорыймын» (Бохари, 2893).

2.

اللّٰهُمَّ لا سَهْلَ إِلاّ ما جَعَلتَهُ سَهلاً، وَأَنْتَ تَجْعَلُ الْحَزَنَ إِذا شِئْتَ سَهْلاً

Аллаһуммә лә сәһлә иллә мә җәгәлтәһү сәһлән, вә әнтә тәҗгәлүл хәзәнә иҙәә ши’тә сәһлән.

Мәгънәсе: «Йә Раббым, Син барлыкка китергәннән башка җиңеллек юк, һәм, теләсәң, Син сагышны җиңеләйтәсең» (Сахих Ибне Хиббән, № 974).

Башка догалар да бар. Коръәннән Юныс галәйһиссәлам догасын укырга мөмкин, мәсәлән:

لَا إِلَٰهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ

**«Синнән башка һичбер илаһ юк! Син пакь! Һичшиксез, мин залимнәрдән булдым!» – дип дәште».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:87

Сезнең догаларыгызның Аллаһыга ирешүенә төп сәбәп – Ислам динендә нык булу, Аллаһы кушканнарны төгәл үтәргә тырышу, тыйганнарыннан тыелу һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтен җиренә җиткереп башкару.

Төшенкелеккә бирелгән вакытта без медицина белгечләренә мөрәҗәгать итәргә дә киңәш итәбез, Коръән белән шифаландыручы белгечләр дә бар. Әмма исегездә тотыгыз, болар – тернәкләнүгә бер тышкы сәбәп кенә, ә тулы дәваны һәм шифаны бары Аллаһы гына бирүче.

Ә Аллаһы яхшырак Белүче!

## Ирләр һәм хатыннар өчен уртак булган аяк киемен кию ирләргә (хатын-кызларга) охшашлануга кермиме?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Шәригатьтә иратларга хатын-кызларга охшашлану тыелган. Заманча аяк киемнәренә карата караш нинди икән? Чөнки бүгенге көндә кедалар, кроссовкалар киеп йөриләр. Мондый аяк киемнәрен кияргә рөхсәт бармы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Әйе, мондый аяк киемнәрен кияргә ярый. Бу очракта аерым бер очрак түгел, ә гадәт әһәмиятлерәк роль уйный. Ислам фикһының нигез принципларының берсе түбәндәгечә яңгырый:

العادة محكمة

«Гадәт хөкем чыгарганда исәпкә алына» («Әшбәх үә ән-нәзаир», 6 нчы кагыйдә, «Мәҗәллә», 36 б.)

Шуны истә тотарга кирәк, бу кагыйдәнең шартлары һәм чикләүләре бар, шуңа күрә бу кагыйдәне куллануның барлык шартларын да белмәгән кеше аны мөстәкыйль рәвештә куллана алмый.

Шулай итеп, хатын-кыз өчен булган аяк киемен хатын-кызлар, ирләр өчен махсус тегелгәнен ирләр кияргә тиеш. Икесе өчен дә уртак булган аяк киемнәрен дә кияргә ярый, әмма кием ирләрнекенә бик охшаган икән, аны кимәү хәерлерәк, яисә, киресенчә, кием хатын-кызныкына бик охшаган икән, аны ирләргә кимәү хәерлерәк. Киемнең мөселманнар яшәгән җирлеккә туры килүенә игътибар итү дә бик мөһим.

Ә Аллаһы яхшырак Белүче!

## Васыятьтә малның бер өлешен мәчет төзелешенә тотарга дип язу ярыймы?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Шәригать буенча мирасның бер өлешен, мәсәлән, 10% ын мәчет төзелешенә тотарсыз дип васыять калдыру дөресме?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Васыятьнамәдә кеше малының бер өлешен кемгә тели яисә нинди максатларга тели, шуңа калдырам дип күрсәтә ала, әмма бу өлеш малның $^1/_3$ е генә була ала, шуннан арткан суммага бирелгән васыять, әгәр варислар риза булмаса, дөрес булмый. Малның бу өлешен санаганда, мәетне күмү чыгымнарын, аның әҗәтләрен исәпкә алырга кирәк.

«Бидая әл-мубтади» китабында болай диелгән:

«Варислар рөхсәтеннән башка малның бары $^1/_3$ өлеше генә васыять итеп бирелә ала. $^1/_3$ өлештән күбрәк малны бары варислар рөхсәте булса гына калдырып була, чөнки бу алар тарафыннан мираска хокуктан баш тарту булып санала. Мондый рөхсәт мирас калдыручы исән вакытта түгел, ә ул үлгәннән соң бирелергә тиешле» (Китап әл-вәсая).

Мисал өчен, мәрхүмнең 100 000 сум акчасы бар, күмү эшләренә 1000, әҗәтләренә 9000 сум китсә, 90 000 сум акча кала. Бу акчаның $^1/_3$ өлеше 30 000 сум. Бу сумма мирас бирүче калдырган васыятьтә күрсәтелгән максатларга тотыла ала.

Сез исә малыгызның 10% ын мәчет төзелешенә кулланырга дип васыять калдыра аласыз, чөнки ул мирасның $^1/_3$ өлешеннән артмый.

Ә Аллаһы яхшырак Белүче!

■ **Булат хәзрәт Мөбарәков, ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе**

# Камил хәзрәт Сәмигуллин мөселман яшьләренә: «Коръәндә барлык сорауларга да җавап бар»



19 нчы сентябрь көнне, Биектау районының "Иске Казан» тыюлыгында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның мөселман яшьләре вәкилләре белән традицион очрашуы узды. Очрашуда бөтен Татарстаннан Нәзарәтнең төрле социаль башлангычларын тормышка ашыручы активистлар, зур мөселман проектларында катнашучы ихтыярчылар, сәләтле мәдрәсә шәкертләре, өметле яшь белгечләр катнашты.

Күркәм гадәт буенча мөфти белән очрашу алдыннан мөселман яшьләре өчен быел да мавыктыргыч спорт-интеллектуаль квест оештырылды. Квестның узу ноктасы шәһәр яны ял базасында булды. Чара башланыр алдыннан анда катнашучыларга ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль бүлек җитәкчесе Айгөл ханым Биктимерова мөрәҗәгать итте. Үзенең чыгышында ул яшьләргә күп кенә мөселман социаль башлангычларны гамәлгә ашыруда зур хезмәт куйганнары, Татарстан өммәте файдасына актив эшчәнлек өчен рәхмәт белдерде.

Аннары яшьләрне ике төркемгә бүлделәр. Егетләр өчен оештыручылар «Батырлар уеннары» квестын үткәрделәр. Уен барышында яшьләр көч, житезлек, саклану күнекмәләренә ия булу өчен көч сынашты. Кызлар өчен исә «Принцессалар балы» квесты үткәрелде. Әкияти принцессалар төрле табышмаклар чиштеләр һәм сынаулар аша уздылар.

Чараның кульминациясе булып Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин белән очрашу торды. Үз чыгышында ул Коръәндә барлык сорауларга да җавап булуын тагын бер кат искә төшерде, һәм «Әлү Гыймран» сүрәсенең безнең белән Аллаһы Тәгалә арасында булган 7 киртә турындагы 14 нче аятен укыды. Коръәндә: **«Күңел тартылган нәрсәләрне: хатыннарны, улларны, кыйнтар-кыйнтар җыелган алтын-көмешне, [яратылышыннан маңгае ак һәм бәдәне ала булып] тамгаланган [токымлы һәм матур аргамак] атларны, [дөя, сыер, сарык һәм кәҗә кебек] терлекне һәм игенлекләрне ярату кешеләр өчен зиннәтләндереп күрсәтелде. Бу – дөнья тормышының [гади, бәһасез мәнфәгатьләрен чагылдырган] нәрсәләре. [Иң] Яхшы кайтачак урын [булган җәннәт] исә – Аллаһы хозурында»,** – диелгән.

Алга таба Татарстан мөселманнары башлыгы һәр киртәнең мәгънәсен аңлатты:

– Кеше юлында булган беренче киртә – хатын-кызларга булган дәрт. Бу авыр сынауны күп кеше уза да алмый. Кыямәт көнендә күләгә астында булачак кешеләрнең җиде төре саналган хәдистә бер кеше турында искә алына: ул кешене чибәр һәм бай хатын-кыз үз янына чакырган, ә ул Аллаһы Тәгаләдән куркуын әйткән. Дәртне җиңү бик авыр. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә безгә «зина кылмагыз», дип кенә әйтми, ә «зинага якын да килмәгез», ди.

Икенче киртә – балаларга булган мәхәббәт. Балаларны яратуда нинди начарлык бар дип әйтергә мөмкиннәр. Ярату – бик яхшы, әмма аларны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен яратырга кирәклеген дөрес аңларга кирәк. Кайвакыт хатын һәм балалар кешене: «Кадерлем, безнең акчабыз аз, аны теләсә ничек тап», – дип, харамга алып килә. Һәм кеше акчаны тыелган алымнар белән эшли башлый.

Өченче киртә – байлык җыю. Кайчагында кеше бу байлыкның колына әйләнә.

Дүртенче киртә – токымлы атлар. Хәзерге вакытта аларны кыйммәтле автомобильләр алмаштыра".

Кешегә баерга мөмкинлек бирә, әмма гыйбадәттән аера торган башка киртәләрне дә Камил хәзрәт санап үтте.

«Һәм шушы җиде әйбер: хатын-кызларга карата дәрт, балаларны, алтынны һәм көмешне, атларны, терлек һәм чәчүлекләрне ярату – боларның барысы да фани дөньяга карый», – дип нәтиҗә ясады Камил хәзрәт.

Аннары яшь мөселман активистлары мөфтигә сораулар бирде. Очрашу ахырында волонтерлар – ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль башлангычларында катнашучылар Татарстан мөфтиенең рәхмәт хатлары белән бүләкләнде. Ахырдан күмәк намазны укып, бәйрәм ашы белән сыйландылар.

Тәкъвалыкка, актив гражданлык позициясенә ия югары белемле, гыйлемле, хәзерге заман шәхесен тәрбияләү, яшьләр арасында үз халкының тарихи-мәдәни мирасына хөрмәт, тормышның рухи-әхлакый кыйммәтләренә өстенлек бирүне тәрбияләү – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлегенең мөһим юнәлеше булып тора. Нәзарәтнең яшьләр сәясәте Коръән кыйммәтләрендә тәрбияләнгән яшь һәм гыйлемле, ихтирамлы, югары әхлаклы, бүгенге заман белән бергә атлаучы шәхес образын яшьләр арасында популярлаштыруга юнәлтелгән. 2019 елда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан яшьләр өчен 19 проект гамәлгә ашырылды. Иң мөһим башлангычлар рәтендә – Мөселман яшьләренең Кышкы һәм Җәйге форумнары, «Яшь вәгазьче» дини конкурсы, «Ислам. Беренче адымнар» бер көндә белем алу мәктәбе, «Кәгазьгә яңа тормыш бүләк ит» хәйрия акциясе, «Мөселман яшьләре фикерләшү клубы», «Яшь килен» мәктәбе, «IMAN» проекты, джиу-джитсу буенча Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Кубокка Бөтенроссия турниры һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең 200-еллыгына багышланган билбау көрәше буенча Халыкара турнир, шулай ук ТР мөфтиенең волонтерлар һәм актив мөселман яшьләре белән очрашулары, ТР мөфтиенең махсус стипендияләре, «Таян Аллага» әдәби бәйгесе һ.б.лар.

**dumrt.ru сайтыннан**



# Коръәндә искә алынган бал корты

Кечкенә бал кортының сөйләгәннәре: «Мин – кечкенә генә бал корты. Аллаһы барлыкка китергән бу якты җир йөзендә миллион, миллиардлаган мәхлүкъ яши. Мин шуларның иң кечкенәләре исәбеннән.

Яратучыбыз миңа югары дәрәҗә биргән, мине калганнар арасыннан аерып алып, Изге Китабындагы сүрәне минем исемем белән атаган. Биредә минем хакта бәян ителә. Боларны белгәч мин бик дулкынландым.

Бу сүрәдә Аллаһы Тәгалә миңа кәрәз ясарга, чакрымнар аша узып, адашмыйча умартама кайту юлын табарга, иң яхшы чәчкәләрне сайлап алып, нектар җыярга һәм аннан бал ясарга өйрәтә.

**«[Расүлем!] Синең Раббың бал кортына вәхи итте: «Тауларда, агачларда һәм [кешеләр төзегән] корылмаларда оялар кор. Шуннан соң, һәртөрле җимешләрдән туклан һәм Раббың җиңеләйткән юлларда йөр». Аларның карыннарыннан [ел фасылларының, чәчәкләрнең, бал кортларының яше үзгәрүгә бәйле] төрле төсле һәм кешеләр өчен шифа булган бер эчемлек чыга. Һичшиксез, боларда фикер йөртүчеләр өчен билге бар».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:68-69

Без бу нәсыйхәтне кабул итеп, геометрик план һәм математик хисап белән эш итеп, алтыпочмаклы кәрәзләр төзибез. Шуннан төрле-төрле чәчкәләрдән серкә җыеп, үз тәнебездә бал әзерлибез. Аннары әлеге бал белән кәрәзләрне тутырабыз. Бу эшләрне калган бал кортлары белән берлектә, эшне тигез итеп бүлеп, хаталар җибәрмәскә тырышып, бар көчебезне куеп башкарып чыгабыз. Тәмле һәм хуш исле бал әзерләр өчен, Раббыбыз өйрәткәнчә, иртәдән-төнгә хәтле хезмәт куябыз. Бу гамәлебез Кыямәт көненә кадәр дәвам итәчәк.

Раббыбыз безнең мисалыбызда бернәрсәне дә максатсыз барлыкка китермәгәнен күрсәтә. Һәр әйбернең үз файдасы һәм кыйммәте бар. Ул безнең барлыгыбызны чолгап алган агачларга, кошларга, төрле чәчәкләргә, елгаларга, миллиардлаган йолдызларга карап, чиксез кодрәткә һәм көчкә ия булган бердәнбер Зат – Аллаһы Тәгалә икәнен аңлавыбызны тели. Безнең өстебезгә җир йөзендәге һәр җан иясенең бәхете өчен тырышу вазифасы йөкләнгән. Боларны онытмасак иде. Сез дә Аллаһының рәхмәте белән әйләнә-тирә мохитне күзәткәндә, безне күргәндә бу сүзләрне исегезгә төшерегез.

Әлбәттә, сез минем исемем белән аталган сүрә хакында белергә телисез. Хәзер мин сезгә аның хакында бәян итәм.

«Ән-Нәхл» дип аталган бу сүрә гарәпчәдән «Бал кортлары» дип тәрҗемә ителә. Сүрә 28 аятьтән тора. Бу аятьләрдә җирләрнең, күкләрнең матурлыгы, анда яши торган мәхлүкъларның үзара күркәм мөгамәләдә тереклек итүләре, кешеләргә хезмәт күрсәтүләре хакында әйтелә.

Шулай ук бу сүрәдә кешеләрнең монда язылганнарга җитди карарга тиешлеге, Аллаһыга гыйбадәт кылуларының мөһимлеге һәм Раббыбызны инкарь итүче кешенең азагы ничек булачагы хакында язылган. Моннан тыш, бу сүрәдә Коръәннең мәгънәләре һәм аның турында фикерләүгә күп урын бирелгән.

Гомумән, сүрәнең эчтәлеген иман, көферлек, гаделлек, яхшылык, фикерләү, акыл, әйткән сүзгә тугры калу, гыйлем, сабырлык һәм тәкъвалык кебек төшенчәләр тәшкил итә.

Сүз уңаеннан, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең барлык җан ияләренә карата мәрхәмәтле булганын белә идегезме? Хәтта сугыш вакытларында да ул үзенең сәхабәләренә: «Хайваннарны үтермәгез, агачларга һәм үләннәргә зыян салмагыз. Балаларга, хатын-кызларга, гыйбадәт кылучыларга, башка дин вәкилләренә һәм аларның гыйбадәт кылына торган урыннарына һөҗүм итмәгез», – дип әйткән.

Бүгенге көн җәмгыяте әлеге үзүзенне тоту кагыйдәләренә бик тә мохтаҗ. Боларны белү мине бик тә дулкынландырды. Расүлебез җир йөзенә мәрхәмәт буларак җибәрелгән кеше иде. Шуңа да безнең кебек кечкенә җан ияләренә карата да шундый күркәм мөнәсәбәттә булды.

**Сәхифәне Айсылу Юлдашева әзерләде**

# Намазның шартлары



## Намазның фарызлары

Намазны дөрес итеп укыр өчен үтәлергә тиешле 12 фарыз бар: шуларның алтысы намаздан тыш һәм аларны намазның шартлары дип атыйлар; алты фарыз – намазда һәм аларны намазның рөкеннәре дип атыйлар.

Намаз кабул ителсен өчен 12 фарызның берсен дә төшереп калдырмыйча барысын да үтәргә кирәк.

## Намазның шартлары

1. Пакьләнү. Бу тәһарәт яисә госел алу юлы белән башкарыла.

2. Нәҗестән чистарыну – пычранган тәнне, киемне һәм намаз кылу урынын чистарту.

3. Гаурәтне каплау. Ир кешенең тәне кимендә кендектән алып тезләренә тикле (тез башларын да кертеп) ябык булырга тиеш. Хатын-кызларның йөзеннән, беләзеккә тикле кулларыннан һәм аяк табаннарыннан кала бөтен тәне капланган булырга тиеш.

4. Кыйбла тарафына юнәлү. Намаз вакытында кыйбла тарафына карап басарга кирәк. Кыйбла – Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылыр өчен Җир йөзендә төзелгән беренче изге бина булган Кәгъбә юнәлеше. Кәгъбә Мәккә шәһәрендәге «Әл-Харам» мәчетендә урнашкан.

5. Вакыт. Намазны үз вакытында укырга кирәк. Намазны вакыты кергәнче яки вакыты чыккач укырга ярамый.

6. Ният. Кайсы намазны укыганыңны белергә һәм йөрәгең белән аны искә алырга кирәк. Ниятне сүз белән әйтү рөхсәт ителә.

## Намазның рөкеннәре

1. Кереш тәкбире. Намаз башында тәкбир әйтү.

2. Кыям. Намаз вакытында басып тору (басып тора алганнар өчен).

3. Кыйраәт. Басып торганда Коръән уку.

4. Рөкүгъ. Билгә тикле баш ию. Рөкүгъта куллар тезләргә куелып, баш белән арка тигез тотыла.

5. Сәҗдә – җиргә тикле баш ию. Сәҗдәдә маңгай, борын, ике кул һәм ике тез идәнгә тидерелә.

6. Соңгы утырыш. Намазның соңында «Әттәхият» укырлык ара утырып тору.

## Рөкеннәрне башкару (Тәгдиле әркән)

Тәгдиле әркән – рөкеннәрне дөрес итеп башкару. Кыямны үтәгәндә, рөкүгъта һәм анан соң тураеп баскач, сәҗдәдә һәм ике сәҗдә арасында гәүдәне беразга селкетмичә тотарга кирәк һәм бу вакыт кимендә «Сүбехәнәллаһил-Гаҙыйм» дип әйтерлек булырга тиеш. Тәгдиле әркән вәҗиб булып санала. Белмичә төшереп калдырган вәҗиб өчен сәһү сәҗдәсе башкарырга кирәк. Әмма намазда тәгдиле әркән үтәлмәгән очракта намазны яңабаштан кылсаң яхшырак була.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шундый кешеләр булыр, аларның намазыннан арыганлык хисеннән башка берни дә калмас», – дип кисәткән (Имам Нәсаи).

Ә башка бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Каракның иң начары – үзенең намазыннан урлап ала торганы» (Имам Әхмәд бине Хәнбәл, Имам Хәким).

## Намазның вәҗибләре

1. Фарыз намазның беренче ике рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсен уку.

2. Фарыз намазларның беренче ике рәкәгатендә, витр, сөннәт һәм нәфел намазларның һәр рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң башка бер сүрә яки өч кыска аять, яисә бер озын аять уку.

3. Бүтән сүрә яки аять алдыннан «Фатиха» сүрәсен уку.

4. Сәҗдәдә маңгай белән бергә борынны да идәнгә тидерү.

5. 3 һәм 4 рәкәгатьле намазларда икенче рәкәгатьтән соң утырып тору (беренче утыру).

6. Намазның беренче һәм соңгы утырышында «Әттәхият»не уку.

7. Намазны җәмәгать белән кылганда имам булган кешенең иртәнге намазда, ахшам һәм ястү намазларының беренче ике рәкәгатендә, бәйрәм, җомга һәм Рамазан аенда тәравих, витр намазларында «Фатиха» сүрәсен һәм башка сүрәне тавыш белән укуы. Ә өйлә һәм икенде намазларын имам булган кеше тавышсыз укый.

8. Имам «Фатиха» сүрәсен һәм башка сүрәләрне укыганда имамга ияргән кешеләрнең тавышсыз торуы.

9. Витр намазында «Конут» догасын уку.

10. Бәйрәм намазларында өстәмә тәкбирләр әйтү.

11. Рөкеннәрне җиренә җиткереп башкару (тәгдиле әркән), ягъни кыямда туп-туры басу, рөкүгъта арканы тигез тоту (хатыннар өчен – бераз иелеп). Рөкүгътан соң төз басып тору. Ике сәҗдә арасында утырып тору.

12. Намаз соңында сәлам бирү.

13. Намазда хаталар булса, сәһү сәҗдәсе кылу:

– фарызлар яки вәҗибләр соңарып башкарылса яки чираты буталса;

– вәҗибләрнең берсе онытылып, төшереп калдырылса;

– намазга намаз хәрәкәтләреннән артык хәрәкәт кушылган булса.

Вәҗибләр белә торып төшереп калдырылса, намазны кабаттан кылырга кирәк.

## Намазның сөннәтләре

1. Фарыз намазларда һәм җомга намазында азан һәм камәт әйтү (хатыннар азан һәм камәт әйтмиләр).

2. Кереш тәкбире вакытында кулларны күтәрү (һәртөрле намазга башлаганда), шулай ук витр намазында «Конут» тәкбирендә һәм бәйрәм намазларының өстәмә тәкбирләрендә кулларны күтәрү. Ирләр кулларын баш бармаклары колак йомшаклыгы биеклегенә җитәрлек итеп күтәрәләр. Ә хатыннар – бармак очлары иңбашлары биеклегендә булырлык итеп.

3. Әүвәлге рәкәгатьтә «Сәнә» догасын уку.

4. Беренче рәкәгатьтә «Сәнә» догасыннан соң «Әгүүҙү» һәм «Бисмилләһ»не әйтергә. Бүтән рәкәгатьләрдә «Фатиха» сүрәсен укыр алдыннан «Бисмилләһи» дип әйтергә.

5. Эчтән генә «Сәнә» догасын, «Әгүүҙү» белән «Бисмилләһ»не уку.

6. Имам «Фатиха» сүрәсен укыганнан соң, моктәди (намазда имамга ияреп намаз укучы) эчтән генә «әәмин» дип әйтә.

7. Ирләр уң кулларын сул куллары өстенә куеп, кендектән бераз астарак тоталар.

8. Бер рөкеннән икенче рөкенгә күчкәндә тәкбир әйтү («Аллаһү әкбәр» дип әйтү).

9. Рөкүгътан соң тураеп басканда «Сәмигаллаһү лимән хәмидәһ» дип әйтү, ә рөкүгътан соң тураеп баскач, «Раббәнә ләкәл хәмде» дип әйтү.

10. Рөкүгъта вакытта «Сүбехәәнә Раббийәл-гаҙыйм» дип, сәҗдәдә «Сүбехәәнә Раббийәл-әгъләә» дип әйтергә.

11. Кыямда чакта аяк табаннары арасындагы ара – 4 бармак киңлегендә.

12. Ирләр рөкүгъта кулларын бармак араларын ачык калдырып тез башларына куялар. Хатын-кызлар бармак араларын ачмый гына кулларын тезләренә куялар.

13. Рөкүгъ вакытында ирләрнең аркалары туры, куллары һәм тезләре бөгелмәгән булырга тиеш. Хатын-кызларның тезләре һәм аркалары бераз (тулаем түгел) бөгелгән була.

14. Сәҗдә кылганда элек идәнгә тезләрне, аннары соң кулларны һәм маңгайны тидерәләр; сәҗдәдән торганда элек маңгай, аннары куллар идәннән аерыла, аннан соң куллар белән ботларга таянып торып басыла.

15. Утырганда кулларны тез өстенә кую.

16. Ирләр сул аяк табанына утыра, уң аяк бармаклары бөгелеп, кыйблага юнәлтелгән рәвештә бастырылып куела. Хатын-кызлар ике аякны да уң якка чыгарып куеп, сул аякка утыралар, аяк бармаклары кыйблага карап тора.

17. Соңгы утырышта «Салават» һәм «Раббәнә» догасын уку.

18. Элек башны уң якка, аннары соң сул якка борып сәлам бирелә.

19. Сәлам биргәндә «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһ» дип әйтү.

20. Намазны башлаганчы алдыңа намаз урынын чикләп торган берәр төрле әйбердән киртә кую.

## Намазның әдәпләре

1. Кыямда вакытта күз карашын сәҗдәдә маңгай тигән урынга юнәлтү.

2. Рөкүгъта чакта аяк очларына карау.

3. Утырган вакытта ботларга карау.

4. Сәҗдәдә борынга карау.

5. Сәлам биргәндә иңбашларына карау.

■ dumrt.ru сайтыннан

# Беренче бөтендөнья сугышы: татар солдатлары күргән авырлыклар


Яшь мөселман солдатларының хәрби ант бирүләре


*Татар морзалары нәселеннән булган Зөлкарнәен Дашкин. Ул Беренче бөтендөнья сугышында 14нче Ырынбур казак полкын җитәкләгән*

1914 елның 1 нче августында Алмания Рәсәйгә сугыш игълан итү белән, Беренче бөтендөнья сугышы (1914-1918) башлана. Иң зур хәрби конфликтта катнаша торган илләр XX гасыр башында ике лагерьга бүленә. Өчлек союзына Алмания, Австро-Венгрия һәм Госманлы империяләре, ә Антантага исә Рәсәй һәм Британия империяләре һәм Франция республикасы керә.

Бу сугышны юкка гына «Беренче бөтендөнья сугышы» дип атамаганнар, чөнки бирегә 70 миллионнан да күп кеше катнашкан. Шуларның 10 миллионы сугыш кырында мәңгелеккә ятып калган. Кайбер фаразлар буенча, гражданнар арасында корбаннар саны 12 миллионга җиткән дип фаразлана. Беренче бөтендөнья сугышын «империяләр зираты» дип тә атыйлар, чөнки бу сугыш аркасында Рәсәй, Госманлы, Австро-Венгрия һәм Алмания кебек зур империяләр юкка чыккан.

Бу сугышта Рәсәй империясенең мөселман гражданнары да катнашкан. Петр патша заманыннан алып, татарлар Рәсәй армиясенә чакырыла торган булган. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан, түбән катлау мөселман татарларының якынча 40 меңе Рәсәй армиясе сафларында хезмәт иткән. Бу барлык түбән катлау кешеләренең 3%нан бераз күбрәге иде.

Ислам динендә булган күпчелек офицерлар татар милләтеннән булган. Ә гомуми мобилизация игълан ителгәннән соң, хәрби хезмәткә чакырылучы солдатлар саны йөзләрчә меңгә җитә башлаган. Кайбер мәгълүматларга караганда, Беренче бөтендөнья сугышында 1 миллионга кадәр татар солдаты катнашкан. Сугыш вакытында Рәсәйдә 19 миллион кеше мобилизацияләнгән, бу ил халкының 10% тан артыграк иде.

Аерым полклар булып формалашкан кавказ мөселманнарыннан үзгә буларак, татарлар катнаш гаскәрләрдә хезмәт иткәннәр. Шуңа күрә хәрби тормышның начар туклану, һава торышы үзгәреп тору, йокы туймау һәм шуның сыман калган авырлыклардан тыш, мөселман татарларына башка өстәмә кыенлыклар белән дә очрашырга туры килә. Мәсәлән, тел белмәү аркасындагы уңайсызлыклар, милли яктан кысрыклаулар, татар телендә аралашуда тыюлар, рационда күпләп яшелчә куллану (ул вакытта татарлар бик аз күләмдә яшелчә ашаганнар), пешекчеләрнең дуңгыз итен әзерләүләре, хәрби имамнарның юклыгы һ.б. бик күп мәшәкатьләр мөселман татарларының тормышын бик нык катлауландырган.

Авыр вакытларда кеше рухи азыкка тагы да мохтаҗ була. Мөселман татарлары мәрхүм булган солдатларны озату, җомга һәм бәйрәм намазларын үткәрү өчен генә түгел, ә яу кырында рух ныклыгын күтәрү һәм тәртип булдыру өчен дә хәрби имамның кирәклеген белдерәләр. Чөнки сугыш кешелек кыйммәтләрен юкка чыгара. Шуңа да кешегә рухи һәм әхлакый яктан нәсыйхәтләр бирелү ихтыяҗы туа.

Бары тик 1916 елда Николай IIнең указы белән Рәсәй гаскәрләренә штатлы дивизион муллалар вазифасы кертелә.

**■ Мөхсин Нурулла язмасы,**
**islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**


Беренче бөтендөнья сугышы. Мөселман солдатлары намаз укый



# Чит кеше кырына кергән үгез

Ибраһим бине Әдһәм болай дип сөйли: «Берьюлы мин хаталанып бер кешенең кырына кердем. Керүем генә булды, хуҗасы миңа: «Әй, үгез! – дип мөрәҗәгать итте. Мин үз-үземә:

– Мин хаталанып чит кешенең кырына кердем һәм минем исемем үзгәрде. Ибраһим бине Әдһәм идем, Үгез булдым. Әгәр барлык гөнаһларым аркасында Аллаһы Тәгалә минем гыйлемемне үзгәртсә, минем белән нәрсә булыр? – дип әйттем».

**Нәсыйхәт:**

Кеше үзе белән булган хәлләрдән дәрес алырга тиеш. Аллаһының дуслары шулай эшли иде. Ибраһим Әл-Әдһәмнең үз-үзен тотышы шуны күрсәтә.

Адәм баласы һәр мизгелендә булган нигъмәтләрен, бигрәк тә иманын һәм гыйлемен, югалту куркынычын истә тотарга тиеш.

# Шәйтан холкының яклары

Вәһб бине Мөнәббиһ рахимәһуллаһи болай дип сөйли: «Нух галәйһиссәлам көймәсеннән коры җиргә төшкәннән соң янына шәйтан килгән. Нух галәйһиссәлам шәйтаннан болай дип сораган:

– Әй Аллаһының дошманы! Кеше холкының кайсы яклары сиңа һәм синең гаскәреңә аны туры юлдан аздырырга ярдәм итә?»

Шәйтан:

– Адәм баласы саран, комсыз, көнче, залим һәм ашыгучан булса, без аны җиңеллек белән харап итәбез. Әгәр мин санап киткән сыйфатлар бер генә кешедә тупланган булса, без бу кешене «үҗәт» дип атыйбыз, чөнки әлеге сыйфатларга баш шәйтаннар ия була», – дип әйткән.

**Нәсыйхәт:**

Кеше холкының начар яклары шәйтанга ярдәм итә һәм кешенең һәлакәткә дучар булуына сәбәпче була.

Саранлык – кабахәт авырту һәм ул зәкят түләүгә комачау итә. Комсызлык харамга ияләшүдә сәбәп булып тора. Гаделсезлек китергән зыянны санап бетерерлек түгел.

Холыкның начар якларыннан котылу өчен тулысынча Ислам кануннары белән яшәргә һәм Аллаһыны зикер итәргә кирәк.

# Хакыйкый мөселманнар

Берьюлы Гайсә галәйһиссәлам таңнәре бик ябык булган, йөзләре саргайган кешеләрне күргән. Аларда гыйбадәт кылу билгеләре булган. Ул алардан:

– Сез нәрсә телисез? (Нигә гыйбадәт кыласыз?) – дип сораган.

Тегеләр:

– Без Аллаһының газабыннан куркабыз, шуңа гыйбадәт кылабыз, – дип җавап биргән.

– Аллаһының рәхмәте киң. Ул сезне ярлыкар.

Пәйгамбәр шул сүзләрне әйткән дә китеп барган. Моннан соң башка халыкларны очраткан. Аларда да гыйбадәт кылу билгеләре күргән. Гайсә галәйһиссәлам шул ук сорауны аларга да биргән:

– Сез нәрсә телисез?

– Без Аллаһының җәннәтен һәм рәхмәтен телибез.

– Аллаһының рәхмәте һәм юмартлыгы чиксез. Ул сезне Үзенең рәхмәтеннән мәхрүм итмәс.

Әлеге сүзләрне әйткәннән соң пәйгамбәр юлын дәвам иттергән. Шул рәвешле тагын бер халыкны очраткан. Аларда тагын да ныграк гыйбадәт кылу билгеләре күреп, кабат шул ук сорауны биргән.

– Сез нәрсә телисез?

Әлеге кешеләр:

– Без Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылабыз, чөнки Ул Безнең Раббыбыз, ә без Аның коллары. Без курку өчен дә, теләк өчен дә гыйбадәт кылмыйбыз, – дип әйткәннәр.

Гайсә галәйһиссәлам боларга:

– Сез ихлас коллар, сез хакыйкый коллар, – дип әйткән.

# Хакыйкый мирас

Берьюлы Зөлкарнәен дуслары белән сөйләшеп утырганда аларның берсе:

– Аллаһы Тәгалә сиңа күп илләр һәм зур хакимлек бирде. Әгәр син хатыннарыңның санын арттырсаң, балаларың күп булыр һәм алар синең нәселеңне дәвам итәрләр, – дип әйтә.

Зөлкарнәен:

– Кешенең хакыйкый нәселе «Мин фәлән-фәләннең улы» (чынлыкта аның балалары булсалар да) дип, аның нәселен дәвам итүчеләр түгел. Кеше үзеннән соң калдырырга тиешле булган хакыйкый мирас – ул Аллаһы Тәгалә һәм әйләнә-тирәдәгеләр риза булырлык күркәм гореф-гадәтләр, дөрес яшәү рәвеше, шулай ук яхшы әхлак, – дип җавап биргән.

**Нәсыйхәт:**

Зөлкарнәен – Коръәннең «Әл-Кәһф» сүрәсендә искә алынучы кеше. Кайберәүләр аны пәйгамбәр дип санаса да, бу мәсьәләдә төрле фикерләр бар. Шулай да иң дөресе – ул Аллаһының яраткан колларының берсе булуы.

Мирас итеп калдырырга тиешле булган әйберләр бар. Шуларның берсе: Исламга каршы килмәгән һәм кешеләргә файда китергән күркәм гореф-гадәтләр. Алар аны үтәүчеләр өчен игелек булып язылып барачак. Икенчесе, Аллаһы риза булган дөрес яшәү рәвеше. Монда кешеләргә ярдәм итү, аларга зыян салмау керә. Болар әлеге кешегә хәерле догалар ирешүгә сәбәп булып тора.

■ **«Рухуль Бәйан» китабыннан**

# Гошер садакасы



Аллаһы Тәгалә бу дөньяга безне гыйбадәт кылыр өчен халык кылды. Раббыбыз иман китергән бәндәләре Аңа якынаю юлларын эзләп, тагын да якынайсын өчен, бөтенесен безгә җиңеллек белән кылган: кечкенә генә бер гамәл өчен дә Ул безгә зур-зур әҗерләрен бирә. Аллаһы Тәгалә Рамазан аенда ихластан ышанган һәм: «Аллаһы Тәгалә гафу итәр», – дип уйлаган ураза тотучының ничәшәр дистә еллар кылынган гөнаһларын да гафу итә. Безгә исә фәкать тырышлык куеп, һәрдаим гыйбадәтләребезне кылу тиешле. Ә гыйбадәтләр арасында күңелгә шатлык, бу дөньяда бәрәкәт һәм кешеләргә сөенеч китерә торган бер гыйбадәт бар: ул да булса – садака, ягъни үз малыңның бер өлешен мескеннәргә, фәкыйрьләргә, ятимнәргә бирү. Мохтаҗ кешеләргә ярдәм иткәч, алардан килә торган рәхмәтлекне һәрберебезнең күргәне яки, һичьюгы, ишеткәне бардыр һәм моны аңлатып кына бетереп булмый. Әле ул яшерен рәвештә бирелсә, гомумән, күңелләр яктыра, чөнки садака алган кешеләр синең өчен ихлас күңелдән дога кыла. Ә андый кешеләрнең догалары кабул була. Шуңа күрә әлеге төр гыйбадәтләрне Аллаһы Тәгалә яшерен, ихластан эшләргә куша һәм савапның иксезчиксез икәнен искәртә. Аллаһы Тәгалә Үзенең мөбарәк китабында безгә болай дип хәбәр итә:

**«Төнлә һәм көндез, яшерен һәм ачыктан-ачык малларын сарыф иткән кешеләргә – Раббылары катында әҗерләре [әзерләп куелган]. Аларга бернинди дә курку булмас, [дөньяда калдырган нәрсәләре өчен] алар хәсрәт тә чикмәс».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:274

Ягъни үз кулы белән эшләп алган малны Аллаһы Тәгалә кушкан җирләргә бирүчеләрне Аллаһы Раббыбыз Үзе зурлый.

Әбү Давыд хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Әгәр бер мөселман киемсез калган бер мөселманны киендерсә, Аллаһы Тәгалә аны җәннәт киеменнән киендерер. Әгәр ач калган кардәшен ашатса, аны да Аллаһы Тәгалә җәннәт ризыкларыннан ашатыр. Сусаган кардәшенә су биреп эчерсә, Аллаһы Тәгалә аны да җәннәт суы белән эчерер.

Шушы ризыкка бәйле садакалар арасында барыбызга да билгеле булган гошер садакасы бар. Бу төр садака иң хәерле һәм бәрәкәтле садакалар төреннән санала. Ә бу садаканы ничек итеп бирергә тиеш соң? Кем нинди күләмдә бирергә тиеш, һәм кемнәргә бирелергә тиеш?

Бу садака яшелчә, җиләк-җимеш белән бирелә. Әгәр алар яңгыр суы белән үстерелгән булсалар, 10нан бер өлеш бирелә, ә инде кеше үзе су сибеп үстергән очракта, 20дән бер өлеш бирелә. Кайбер кешеләрдә түбәндәге ялгыш фикер дә йөри: имеш, бәрәңгедән 10нан 1 өлеш, ә бүтән яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән 20дән бер өлеш кенә бирелә . Әмма бу фикер – ялгыш. Яңгыр суы белән үскән барлык үсемлек: җиләк-җимеш, яшелчә һ.б. ризыклардан садака итеп 10нан 1 өлеш бирергә кирәк.

Әмма бер күңелсез хәл дә бар: бүгенге көндә күп кешеләр шушы гыйбадәттән (изге гамәлдән) баш тарталар. Үзләренә аргумент итеп: «Мин үзем тир түгеп үстергән малымны кемгәдер илтеп бириммени? Бөтен кешегә өләшсәм, миңа нәрсә калыр? Миңа берәүнең дә китереп биргәне юк бит әле», – дигән фикерләр китерәләр. Әлбәттә, бу халыкның гыйлемсезлеге аркасында һәм Аллаһы Тәгаләгә тиешле рәвештә тәвәккәл кылмаганлыктан килеп чыга. Без бит бакчага әйбер утыртканда уңышның бик күп булуын телибез. Ә үзебез шөкер итү йөзеннән әз генә булса да малны корбан итмибез, ягъни өлеш чыгармыйбыз. Әгәр дә шулай уйлыйм икән, мин нинди күңел белән шул уңышны өмет итәргә тиеш инде?! Шунлыктан, сүзләрне әйткәндә, нинди дә булса карар кылганда, уйлап эш итәргә кирәк.

Садакаларны кемнәргә бирергә кирәк соң? Гадәттә, безнең җирлектә бу хәерне мохтаҗ кешеләргә, мәдрәсәләргә, мәчетләргә тапшыралар. Чыннан да, бу садаканы фәкыйрь, мескен, ятим кешеләргә, гыйлем алу юлындагы шәкертләргә, ялгыз яшәүче әби-бабайларга бирергә мөмкин. Бу акчалата бирелгән садакадан да шул ягы белән аерылып тора: авыр хәлдәге гаиләләргә акчалата садака биргәндә, алар аны дөрес юлларга кулланмаска да мөмкиннәр. Ә ризык белән биргәндә, мондый проблема булмаячак. Мин үзем, шәхсән, дөньяви уку йортларында укучы һәм тулай торакларда яшәүче мөселман егет-кызларга тапшыргалыйм. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Садака малны киметми», – дип әйткән, шулай булгач, садакаларыбызны тапшырыйк. Бер капчык уңышыбызны садака итеп тапшырудан беркем дә ач яки ярлы булып калмаячак, Аллаһыга шөкер, без бүгенге көндә туклык заманында яшибез. Әгәр җиләкҗимештән үзебез өчен төрле кайнатмалар ясыйбыз икән, аннан да гошерне бирү тиешле була.

Ислам динендәге һәр бәйрәм, һәр садака, һәр гыйбадәт кешеләр арасын якыйнайтыр, сөендерер өчен боерылган. Шуңа да бер өммәт булып, берберебезгә ярдәм итешеп яшик. Кардәшенә ярдәм иткән кешегә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм итә. Әгәр дә без мохтаҗларга ярдәм итсәк, Аллаһы Тәгалә дә безгә ярдәм итәр. Аллаһы Тәгалә һәрбарчаларыбызга ике дөньяның да бәхетен насыйп кылсын.

■ **Алмаз хәзрәт Галимҗанов, Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе, Сатыш авылы имам-хатыйбы**

# Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлек китерү

Ширек – ул Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлек китерү һәм Аллаһы Тәгалә белән беррәттән ул нәрсәгә/кемгә гыйбадәт кылу. Икенче төрле әйткәндә – илаһландыру. Илаһландыра торган әйберләр яки затлар булып кеше, кояш, ай, пәйгамбәр, шәех, җен, йолдыз, хаким һәм аларга охшашлар тора ала. Ширек турында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Һичшиксез, Аллаһы Үзенә ширек кушылуын ярлыкамый. Моңардан тыш булганны исә Үзе теләгән кешегә ярлыкар. Кем дә кем Аллаһыга ширек кушса, ул бик зур бер гөнаһ ялган уйлап чыгарган булыр».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:48

**«... [Бернәрсәне дә] Аллаһыга ширек кушма. Һичшиксез, ширек – бик зур золым».**

«Локман», 31:13

Бүтән илаһларга гыйбадәт кылып, мөшрик халәтендә үлгән кеше җәһәннәм әһеле булачак. Ә бу дөньяны йөрәгендә иман белән үткән кеше, нинди генә гөнаһлар кылуына һәм алар өчен җәзалар алуына карамастан, ахыр чиктә җәннәткә керәчәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен тапшыралар: «Кылырга мөмкин булган иң зур гөнаһ турында беләсегез киләме? Ул – ширек!» (Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиде һәлакәткә китерә торган гөнаһтан сакланыгыз...», – дип әйтте һәм алар арасында ширекне дә искә алды.

Түбәндәге хәдисне Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе болай дип тапшыра: «Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләреннән өч тапкыр: «Сезгә иң авыр гөнаһлар турында хәбәр биримме?» – дип сорый. Алар: «Әлбәттә, йә, Аллаһының Расүле», – диделәр. Шунда ул: «Ул – ширек һәм ата-анага буйсынмау», – дип әйтте. Ул бу сүзләрен әйткән вакытта кырын ята иде, шуннан соң, бераз гына торып: «Һәм ялганнан сакланыгыз», – дип өстәп куйды. Ул бу сүзләрен кат-кат әйтә башлагач, алар (сәхабәләр): «Ий, туктаса гына ярар иде», – дип әйтергә мәҗбүр булдылар.

Ширек төрләреннән – рия да бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин сезнең өчен кечкенә ширектән куркам», – дип әйтте. Алар: «Йә, Расүлуллаһ, нәрсә ул кечкенә ширек?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул – рия», – дип әйтте.

# Кеше үтерү гөнаһы



Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

**«Кем дә кем [иманлы булганы өчен, яки үтерелүен хәләл күреп] максатлы рәвештә бер мөэминне үтерсә, аның җәзасы – эчендә мәңге калачак җәһәннәм. Аллаһы аңа ачуланды, аны ләгънәт итте һәм аңа бик зур газап әзерләде»;**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:93

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиде һәлакәткә китерә торган гөнаһтан сакланыгыз: ширек кылу, сихерчелек, кеше үтерү, ятимнең малын ашау...», – дип әйткән.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Иң зур гөнаһ нинди?», – дип сорадылар. Ул: «Сине барлыкка китергән Аллаһыга тиңдәшлек китерү», – дип җавап кайтарды. Сәхабәләр: «Ә аннан соң?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ризык җитмәс дип куркып, үзеңнең балаңны үтерү...», – дип җавап кайтарды.

Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: Әгәр ике мөселман кылычларын кисештереп, берсе икенчесен үтерсә, алар икесе дә җәһәннәмгә эләгәләр», – дип әйтте. Сәхабәләр аннан: «Йә, Аллаһының Расүле, үтерүченең хәле аңлашыла. Әмма ник үлгән кеше дә җәһәннәмгә эләгә соң?» – дип сорадылар. Ул: «Аның да үтерергә нияте булганы өчен», – дип җавап кайтара.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә тыйган кешене үтерүдә булышканчыга кадәр, кеше тынычлыкта яшәр», – дип әйткән. Бу хәдиснең икенче риваятендә болай дип әйтелә: «Аллаһы Тәгалә җәннәт ишекләреннән кертмичә калдырган бер генә дә кол да булмас, иллә мәгәр ул кеше Аллаһыга ширек китергән яки кеше үтерүдә бергә катнашкан кеше генә булмаса».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин үлгәч, бер-берегезне үтерүче кяферләргә әйләнмәгез», – дип әйтә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тыелган канны түккәнчегә кадәр мөэмин тынычлыкта яшиячәк». «Кыямәт көнендә иң беренче мәсьәләләрдән булып кан коелу торачак», – дип әйткән.

Габдулла бине Гамердән риваять ителә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иң авыр гөнаһлар булып ширек кылу, кеше үтерү һәм ата-анага итагать итмәү тора», – дип әйткән.

Готбә бине Мәликтән тапшырыла, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә мөэминне үтергән кешедән читкә борылачак», – дип әйткән һәм шуны тагын 3 тапкыр кабатлаган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гаделсезлек белән кемне генә үтерсәләр дә, коелган кан өчен җаваплылыкның бер өлеше Адәм баласына (Кабил турында сүз бара) төшәчәк, чөнки үтерүгә юлны ул ачты», – дип әйткән.

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять кылына: Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Канун яклаган кешене үтерүче җәннәтнең исен дә тоя алмас, гәрчә аның исе 40 ел юл озынлыгында ук тоела башлый», – дип әйткән.

Имамнар Бохари һәм Ән-Нәсаи Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән түбәндәге хәдисне китерәләр: Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: Игътибар! Аллаһы Тәгалә һәм Аның Расүленең сагы астында булган кешенең гомеренә кул сузган кеше Аллаһыга да каршы төшкән була, һәм ул җәннәтнең исен дә тоя алмас, гәрчә аның исе 40 ел юл озынлыгында ук тоела башлый», – дип әйткән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителә: Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Берәр мөселманны ярты сүз белән генә булса да үтерергә булышкан кеше Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршына маңгаенда «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән мәхрүм» дигән язу белән басачак», – дип әйткән (Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан).

Могавия радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезнең түбәндәге сүзләрен риваять кыла: «Имансыз булып үлүдән һәм мөселман кешене үтерүдән кала, барлык гөнаһлар өчен ярлыкануны өмет итәргә мөмкин», – дип әйткән (Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан).

■ **Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан**

### ДҮШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 МИМ
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Бер хәдис – бер җавап
11:40 Җан авазы
11:50 Иң гүзәл исемнәр12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
13:15 «Малец-Удалец» мультфильм
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 МИМ
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Бер хәдис – бер җавап
20:40 Җан авазы
20:50 «Иң гүзәл исемнәр»
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 «Разговоры о важном»
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

### СИШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
08:30 «Таз Малай» мультфильм
08:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:00 «Иң гүзәл исемнәр»
09:10 Балам-багалмам
09:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:50 Хикмәтле хикәяләр
10:00 Намазга өйрәник
10:20 Бер хәдис – бер җавап
10:30 «Тәфсир дәресләре» Тимергали Юлдашев
11:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:15 Гаилә дәресләре
11:45 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 Шекер Ходжа
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Ученые Ислама
13:20 Есть вопрос – есть хадис
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
17:30 «Таз Малай» мультфильм
17:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:00 Иң гүзәл исемнәр
18:10 Балам-багалмам
18:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:50 Хикмәтле хикәяләр
19:00 Намазга өйрәник
19:20 Бер хәдис – бер җавап
19:30 «Тәфсир дәресләре» Тимергали Юлдашев
20:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:15 Гаилә дәресләре
20:45 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ученые Ислама
22:20 Есть вопрос – есть хадис
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### ЧӘРШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 МИМ
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Бер хәдис – бер җавап
11:40 Җан авазы
11:50 «Иң гүзәл исемнәр»
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
13:15 «Малец-Удалец» мультфильм
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 МИМ
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Бер хәдис – бер җавап
20:40 Җан авазы
20:50 Иң гүзәл исемнәр
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана и толкование на татарском языке

### ПӘНҖЕШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
08:30 «Таз Малай» мультфильм
08:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:00 «Иң гүзәл исемнәр»
09:10 Балам-багалмам
09:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:50 Хикмәтле хикәяләр
10:00 Намазга өйрәник
10:20 Бер хәдис – бер җавап
10:30 «Тәфсир дәресләре» Тимергали Юлдашев
11:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:15 Гаилә дәресләре
11:45 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 Шекер Ходжа
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Ислам без стереотипов
13:20 Халяль-лайфстайл
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
17:30 «Таз Малай» мультфильм
17:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:00 «Иң гүзәл исемнәр»
18:10 Балам-багалмам
18:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:50 Хикмәтле хикәяләр
19:00 Намазга өйрәник
19:20 Бер хәдис – бер җавап
19:30 «Тәфсир дәресләре» Тимергали Юлдашев
20:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:15 Гаилә дәресләре
20:45 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ислам без стереотипов
22:20 Халяль-лайфстайл
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### ҖОМГА


07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 «Иң гүзәл исемнәр»
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Минбар
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
13:15 «Малец-Удалец» мультфильм
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 Иң гүзәл исемнәр
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Минбар
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана и толкование на татарском языке

### ШИМБӘ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
08:30 Балам-багалмам
08:50 «Иң гүзәл исемнәр»
09:00 «Таз Малай» мультфильм
09:15 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:30 Хәзинә
09:45 Һөнәрләр
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Әлифба сабаклары
10:45 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:00 «Мәслихәт»
11:20 Хәдис дәресләре
11:40 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 Шекер Ходжа
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Ислам без стереотипов
13:20 Халяль-лайфстайл
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
17:30 Балам-багалмам
17:50 Иң гүзәл исемнәр
18:00 «Таз Малай» мультфильм
18:15 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:30 Хәзинә
18:45 Һөнәрләр
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Әлифба сабаклары
19:45 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:00 «Мәслихәт»
20:20 Хәдис дәресләре
20:40 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ислам без стереотипов
22:20 Халяль-лайфстайл
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### ЯКШӘМБЕ

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 «Иң гүзәл исемнәр»
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Минбар
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
13:15 «Малец-Удалец» мультфильм
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз өчендә хикмәт бар»
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 «Иң гүзәл исемнәр»
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Минбар
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана и толкование на татарском язык




# «АЛТЫ БАРМАК. Мөхәммәднең олуг өстенлекләре» китабы дөнья күрде

ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты Муинуддин Мөхәммәд Әмин Хиравиның «Алты Бармак. Мөхәммәднең олуг өстенлекләре» дип аталган китабын бастырды. Әлеге китап XX гасыр башында татар имамнары арасында киң таралган була. Һәрбер татар кешесенең өстәл китабы булып та нәкъ менә шушы китап саналган. Шуңа өстәп, мәдрәсәләребездә Аллаһы Расүленең тормыш юлы буенча уку әсбабы итеп тә әлеге хезмәт сайланган. «Алты Бармак»та һәрьяклап Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы ачыла. Шулай ук китапта башка пәйгамбәрләр һәм илчеләр турында да тәфсилләп мәгълүмат бирелә.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.

**Кибет:** Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт.
Тел.: +7 960 072-74-63
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru (http://huzurshop.ru/)




## «Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2020 елның икенче яртыеллыгына язылу дәвам итә

- Ярты елга язылу бәясе: 156 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин: podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 598 09 42


## КАЗАН ӨЧЕН ОКТЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Көн Исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.10.2020 | Пәнҗ | 03:42 | 04:16 | 05:46 | 12:00 | 15:18 | 17:18 | 18:59 |
| 02.10.2020 | Җом | 03:44 | 04:18 | 05:48 | 12:00 | 15:15 | 17:15 | 18:57 |
| 03.10.2020 | Шим | 03:46 | 04:20 | 05:50 | 12:00 | 15:13 | 17:13 | 18:54 |
| 04.10.2020 | Якш | 03:48 | 04:22 | 05:52 | 12:00 | 15:11 | 17:10 | 18:51 |
| 05.10.2020 | Дүш | 03:50 | 04:24 | 05:54 | 12:00 | 15:08 | 17:08 | 18:49 |
| 06.10.2020 | Сиш | 03:52 | 04:26 | 05:56 | 12:00 | 15:06 | 17:05 | 18:46 |
| 07.10.2020 | Чәрш | 03:55 | 04:28 | 05:58 | 12:00 | 15:04 | 17:02 | 18:43 |
| 08.10.2020 | Пәнҗ | 03:57 | 04:30 | 06:00 | 12:00 | 15:02 | 17:00 | 18:41 |
| 09.10.2020 | Җом | 03:59 | 04:32 | 06:02 | 12:00 | 14:59 | 16:57 | 18:38 |
| 10.10.2020 | Шим | 04:01 | 04:34 | 06:04 | 12:00 | 14:57 | 16:55 | 18:36 |
| 11.10.2020 | Якш | 04:03 | 04:36 | 06:06 | 12:00 | 14:55 | 16:52 | 18:33 |
| 12.10.2020 | Дүш | 04:05 | 04:38 | 06:08 | 12:00 | 14:53 | 16:50 | 18:31 |
| 13.10.2020 | Сиш | 04:07 | 04:40 | 06:10 | 12:00 | 14:50 | 16:47 | 18:28 |
| 14.10.2020 | Чәрш | 04:09 | 04:42 | 06:12 | 12:00 | 14:48 | 16:45 | 18:26 |
| 15.10.2020 | Пәнҗ | 04:11 | 04:44 | 06:14 | 12:00 | 14:46 | 16:42 | 18:23 |
| 16.10.2020 | Җом | 04:13 | 04:46 | 06:16 | 12:00 | 14:44 | 16:40 | 18:21 |
| 17.10.2020 | Шим | 04:15 | 04:48 | 06:18 | 12:00 | 14:41 | 16:37 | 18:19 |
| 18.10.2020 | Якш | 04:17 | 04:50 | 06:20 | 12:00 | 14:39 | 16:35 | 18:16 |
| 19.10.2020 | Дүш | 04:19 | 04:52 | 06:22 | 12:00 | 14:37 | 16:32 | 18:14 |
| 20.10.2020 | Сиш | 04:21 | 04:54 | 06:24 | 12:00 | 14:35 | 16:30 | 18:12 |
| 21.10.2020 | Чәрш | 04:23 | 04:57 | 06:27 | 12:00 | 14:33 | 16:28 | 18:10 |
| 22.10.2020 | Пәнҗ | 04:25 | 04:59 | 06:29 | 12:00 | 14:30 | 16:25 | 18:07 |
| 23.10.2020 | Җом | 04:27 | 05:01 | 06:31 | 12:00 | 14:28 | 16:23 | 18:05 |
| 24.10.2020 | Шим | 04:29 | 05:03 | 06:33 | 12:00 | 14:26 | 16:21 | 18:03 |
| 25.10.2020 | Якш | 04:31 | 05:05 | 06:35 | 12:00 | 14:24 | 16:18 | 18:01 |
| 26.10.2020 | Дүш | 04:32 | 05:07 | 06:37 | 12:00 | 14:22 | 16:16 | 17:59 |
| 27.10.2020 | Сиш | 04:34 | 05:09 | 06:39 | 12:00 | 14:20 | 16:14 | 17:57 |
| 28.10.2020 | Чәрш | 04:36 | 05:11 | 06:41 | 12:00 | 14:18 | 16:12 | 17:55 |
| 29.10.2020 | Пәнҗ | 04:38 | 05:13 | 06:43 | 12:00 | 14:16 | 16:09 | 17:53 |
| 30.10.2020 | Җом | 04:40 | 05:15 | 06:45 | 12:00 | 14:14 | 16:07 | 17:51 |
| 31.10.2020 | Шим | 04:42 | 05:17 | 06:47 | 12:00 | 14:12 | 16:05 | 17:49 |


ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Сентябрь саны, №9 (302)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2753
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 29 нче августта таратыла.
График буенча бу санга 28 нче сентябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.